Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советының егерме дүртенче утырышы

Колай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

16 июнь, 2020 ел № 74

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советының «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 26 статьясы белән йортларны файдалануга тапшыруга бәйле рәвештә, расланган чикләр кысаларында бер мандатлы сайлау округларының гамәлдәге схемасын төгәлләштерү максатларында **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кулай авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм төгәлләштерүләрне кертергә:

1.1. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге Советы карарына кушымта 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы) кертеп, түбәндәгеләрне кертергә:

а) Колай бер мандатлы сайлау округына Колай авыл җирлегенең Мишә утарлары дача кулланучылар кооперативының 8 нче терреториясен;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская